ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КҮӘМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

КУБЯНСКИЙ СЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422740 Республика Татарстан Атнинский район с. Кубян. Тел. 3-63-39

# КАРАР

12.07.2019 г. № 8

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
бюджетыннан алынучы башка бюджетара
трансфертлар исәбенә башкарылучы
чыгымнар юнәлешен раслау турында

Һөнәри керемгә салым буенча салым потенциалы үсүен стимуллаштыру максатыннан, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 9 апреленнән 102 нче номерлы "Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы җирлекләре бюджетларына җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен башкаруны финанс тәэмин итүгә башка бюджетара трансфертлар тәкъдим итү Тәртибен раслау турында"гы карарына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2003 елның 6 октябреннән № 131-ФЗ "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы Федераль законның 14 маддәсенә ярашлы төстә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы бюджетыннан алынучы башка бюджетара трансфертлар исәбенә башкарылучы чыгымнар юнәлешен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен расларга.

2. Бу карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырырга (халыкка чыгарырга).

3. Әлеге карар үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Әтнә муниципаль районы
Күәм авыл җирлеге җитәкчесе Гатауллин Р.Р.